Республика Татарстан

**СОВЕТ СТАРОКАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Комсомола, д. 4а, с. Старый Кашир
423357
Телефон: 4-86-36

**Татарстан Республикасы**

**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КӘШЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГ СОВЕТЫ**

Комсомол урамы, йорт 4а, Иске Кәшер авылы 423357
Телефон: 4-86-36

---

**РЕШЕНИЕ** **№16** **КАРАР**

2020 елның 14 декабре Иске Кәшер авылы

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы (ред. 13.03.2020) Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Иске Кәшер авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымта «Сарман муниципаль районы «Иске Кәшер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү турында нигезләмәгә» түбәндәге эчтәлекле 6,7,8 пунктлар өстәргә:

«6. Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затның еллык түләүле отпуск төп түләүле отпускстан һәм өстәмә түләүле отпускстан тора.

7. Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затлар өчен ел саен түләнә торган төп түләүле отпуск дәвамлылыгы муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә, ләкин 30 календарь көннән дә ким булмаска тиеш.

8. Тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгы муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка муниципаль вазыйфаны биләгән һәр ел өчен календарь көн, муниципаль хезмәт вазыйфасын, шулай ук дәүләт вазыйфасын һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән өчен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә. Еллык төп түләүле отпускның һәм муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче зат өчен, тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның гомуми дәвамлылыгы 45 календарь көннән арта алмый.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге
башлыгы

Р.Н.Дәүләтҗанов